

Афганистанда тугыз елдан артык дәвам иткән сугыш безнен республиканы да читләп узмый. Шул каночкеч сугышта Мордовиядән 3000 кеше катнашты; 68 - вафат, ә 48 инвалид булып кайтты.

15 февральдә Республикабызнын Мәдәният йортында vткәрелгән тантанага республикабызнын афганчы-ветераннары жыелды. Ватаныннан читтә хәрби бурычын vтәгән россиялеләргә багышланган Хәтер конендә Мордовия Главасы Владимир Волков исеменнән Госсобрание житәкчесе Владимир Чибиркин белән «Боевое братство» Ботенроссия ижтимагый оешмасы региональ бvлеге рәисе Валерий Миточкин тәбрикләп изге теләкләрен житкерделәр, сугыш турында сойләделәр һәм сугышчы-интернационалистларга лаеклы бvләкләр дә тапшырдылар. Ә кичә алдыннан регионыбыз афганчы-ветераннары Саранск шәһәрендәге һәйкәлгә гирляндалар, чәчәкләр куйдылар. Kvп еллардан бирле дәвам итә торган kvркәм гадәт буенча, алар быел да дини урыннарга барып дога кылдылар.

Тантанада Владимир Чибиркин болай ди: «Эхо десятилетия афганских событий до сих пор тяжелым набатом отдается в сердцах нашего народа. Мы помним защитников Отечества – воинов-интернационалистов, помним, через что им пришлось пройти и какие выдержать испытания. И какими бы противоречивыми не были оценки Афганской войны, мы точно знаем, что наш солдат стоял на защите национальных интересов, обеспечивал безопасность Отчизны... » Ул чыгышында: «Через службу в Афганистане прошли почти три тысячи уроженцев Мордовии (2956 человек), 629 из них отмечены орденами и медалями. 68 погибли. Более тысячи семисот воинов-афганцев проживают сейчас в республике».



Владимир Чибиркин әйткәнчә, регионыбыз житәкчесе сугышта катнашкан ветераннарнын киләчәк буынга патриотик һәм әхлакый тәрбия бирүдә керткән олешләрен, Мордовиянен ижтимагый-сәяси тормышында активлыкларын югары бәяли: «Ваши опыт, знания, профессионализм очень нужны сейчас стране и респуб-лике. Своим примером вы показываете молодежи, как следует относиться к судьбе России, к истории, культуре и традициям народа, как можно бескорыстно и беззаветно любить Родину».
Соныннан бүләкләр тапшырылды: Айса Рәстәм улы Хабибуллинга «Батырлык очен» («За ратную доблесть») медале, Фаиль Ильяс улы Жалимовка һәм Марат Зыя улы Сайфулловка Мордовия Хормәт грамотасы (Почетная грамота), Камиль Абдрашит улы Заликовка Мордовия Госсобрание Рәисе Рәхмәте.
«Боевое братство» Ботенроссия ижтимагый оешмасы региональ бүлеге рәисе Валерий Миточкин афганчылар истәлегенә бер минутлык тынлык белдерде.
Сугышчы-интернационалистлар турында сойләде, аларны шул кон белән котлады һәм бүләкләр тапшырды.
Афганчылар хормәтенә «Афганское эхо» дигән XXX Республика патриотик жыр фестивале лауреат һәм дипломантлары матур концерт бүләк иттеләр.
Рәсемдә сулдан унга: Ринат Альмяшев, Фаиль Жалимов, Раиль Невлютов, Марат Сайфуллов.

Наилә Насырова